Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 май 2020 ел №373

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины турында»гы 72 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 19 маендагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданины турында»гы 72 нче номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 19 октябрендәге 234 нче номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 18 нче номерлы, 2015 елның 29 декабрендәге 45 нче номерлы, 2016 елның 10 августындагы 85 нче номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 204 нче номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 306 нчы номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 347 нче номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 369 нче номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче кушымтаның 3.6 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Мактаулы гражданинның шәхси гаризасы нигезендә район бюджетын үтәү процессында алынган өстәмә керемнәр хисабына аена 7,5 мең сум (җиде мең биш йөз сум) исәбеннән коммуналь хезмәтләр өчен чыгымнарны каплау. Шәхси гариза бирү вакыты елның беренче 30 календарь көне эчендә;»;

1.2. карарга 3 нче кушымтаның 3.10 пунктындагы икенче, өченче, дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район бюджетын үтәү процессында өстәмә алынган керемнәр хисабына түбәндәгеләр башкарыла:

- вафат булган Мактаулы гражданинны җирләүне оештыру һәм күмү чыгымнары мәрхүмнең туганнарының мөрәҗәгате нигезендә,үлгәннән соң 6 ай эчендә, Россия Федерациясендә билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең 10 минималь күләменнән артмаган күләмдә кире кайтарыла;

- вафат булган Мактаулы гражданинга кабер ташын ясау һәм урнаштыруга чыгымнарны, мәрхүмнең туганнары мөрәҗәгате нигезендә, Россия Федерациясендә билгеләнгән 10 минималь хезмәт хакы күләменнән артмаган күләмдә кайтарыла.».

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3.1. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пунктчасындагы нигезләмәләр, агымдагы елда әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Салахов И.Р.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов